**Республика Татарстан**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» апрель, 2021 ел № 291

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч, Кощаково, Пановка авылы территориясендә «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу (канализация) системасына агынты суларны агызу (җибәрү) белән шөгыльләнүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законнарын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы «Агынты суларның составын һәм үзлекләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында»гы карарлары белән туры китерү, әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләрнең тискәре йогынтысын, су объектларының пычрануын кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч, Кощаково, Пановка авылы территориясендә «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу (канализация) системасына агынты суларны агызу (җибәрү) белән шөгыльләнүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын, әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.

2. «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына (канализация) агызучы барлык абонентларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының

Питрәч, Кощаково, Пановка авыллары территориясендә агып җыела торган суларның составы нормативларын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының карарына кушымта

_______________ № ____

# «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына агызучы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативлары

| N п/п | Матдәләр исеме | Агынты суларның составы нормативлары, мг/дм3 |
|---|---|---|
| 1 | Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| 2 | Кислородны химик куллану, ХПК | 500 |
| 3 | БПК5 | 300 |
| 4 | Коры калдык | 1341 |
| 5 | Аммоний-ион | 25 |
| 6 | Фосфат-ион (по Р) | 12 |
| 7 | Фенол | 0,053 |
| 8 | Формальдегид | 0,039 |
| 9 | Нефть продуктлары | 0,149 |
| 10 | АСПАВ | 0,26 |
| 11 | Тимер | 0,39 |
| 12 | Алюминий | 0,08 |
| 13 | Хром 6+ | 0,02 |
| 14 | Хром 3+ | 0,01 |
| 15 | Бакыр | 0,003 |
| 16 | Цинк | 0,042 |
| 17 | Никель | 0,024 |
| 18 | Кадмий | 0,0001 |
| 19 | Кургаш | 0,002 |
| 20 | Марганец | 0,018 |
| 21 | Кобальт | 0,02 |
| 22 | Хлорид-анион | 136,5 |
| 23 | Фторид-анион | 0,223 |
| 24 | Сульфат-анион | 106,2 |
| 25 | Сульфид-анион | 0,2 |
| 26 | Ванадий | 0,001 |
| 27 | Хлороформ | 0,0032 |